ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АГРАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

КАРАР

№ 26 12.03.2025 ел.

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Аграмак авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Аграмак авыл җирлеге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының бүленгән полосаларын һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм алардан файдалану тәртибен раслау турында» 2022 елның 02 ноябрендәге 46 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының бүленгән полосаларын һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм алардан файдалану тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Җир кодексына, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм «Россия Федерациясе Җир кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 5 статьясындагы 2 өлешенең үз көчен югалтуын тану хакында» 2024 N 485-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Аграмак авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының бүленгән полосаларын һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм алардан файдалану тәртибенә «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының бүленгән полосаларын һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм алардан файдалану тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге башкарма комитетының 2022 елның 02 ноябрендәге 46 номерлы карары белән расланган түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.1 пунктта "керемнәрдән тыш" сүзләреннән соң "дүртенче һәм бишенче категорияле автомобиль юллары һәм" сүзләрен өстәргә.;

1.2. 3.8 пунктта «килешүен» сүзен «килештерүне» сүзенә алмаштырырга;

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында http://spasskiy.tatarstan.ru һәм хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы Спас муниципаль
Районының Аграмак авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Р.Т.Галәветдинова.

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРАМАКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «АГРАМАКОВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИНН 1637005496